УДК 82.512.145

*Р.Г. Зәкиева*

# КАЮМ НАСЫЙРИ – ХАЛЫККА ХЕЗМӘТТӘ
## (галим эшчәнлегенә багышланган яңа хезмәтләр хакында)

(«Каюм Насыйри: Биобиблиографик күрсәткеч» / Р.Ф. Исламов. Казан: ТР ФА М. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2024. 160 б.; «Каюм Насыйри: иллюстрацияле персональ энциклопедия» / төз.-авт.: Р.В. Шәйдуллин, Р.Ф. Исламов, Ф.С. Гыйниятуллина, Ф.Г. Камальтдинова, И.Х. Хәлиуллин, Ф.Р. Бәдретдинова, Г.И. Каюмова. Казан: ТР ФА М. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2025. 500 б.)

2025 елда мәгърифәтче, тел галиме, язучы, тарихчы, этнограф, энциклопедист галим Каюм Насыйриның (1825–1902) тууына 200 ел тулды. Каюм Насыйри – бөтен тормышын, талантын халыкка хезмәт итүгә багышлаган күренекле шәхесләрнең берсе.

2023 елның 22 мартында Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуны билгеләп үтү уңаеннан уздырыласы чаралар турындагы Указга кул куйды. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты да бу чаралардан читтә калмады. 2024 елда филология фәннәре докторы, институтның Энциклопедистика үзәге баш гыйльми хезмәткәре Рәмил Исламовның «Каюм Насыйри: Биобиблиографик күрсәткеч» дип исемләнгән хезмәте, 2025 елда институт галимнәре тарафыннан әзерләнгән «Каюм Насыйри: иллюстрацияле персональ энциклопедия» китабы дөнья күрде (проектның җитәкчесе – тарих фәннәре докторы, профессор Рафаил Шәйдуллин).

Бүгенге көнгә кадәр мәгърифәтченең библиографик күрсәткече аерым китап итеп нәшер ителмәгән иде. Әлбәттә, аның библиографиясен булдыруга омтылышлар ясала. Галимнең тууына 120 ел тулуга багышлап уздырылган гыйльми сессия материаллары җыентыгында әдәбият галиме М.Х. Гайнуллин тарафыннан төзелгән «Библиографик белешмәләр» урнаштырыла [4: 142–145]. Ул «Каюм Насыйриның басылып чыккан әсәрләре» һәм «Каюм Насыйри турында рус һәм татар матбугаты» дигән ике өлештән тора. Белешмәнең тулыландырылган варианты З.Ш. Хәбибуллина тарафыннан 1952 елда аерым китапчык итеп бастырыла [5: 12]. К. Насыйриның тууына 150 ел тулу уңаеннан 1975 елның 14 февралендә үткәрелгән конференция материаллары тупланмасында әлеге юбилей чаралары белән бәйле рәвештә матбугатта басылып чыккан мәкаләләрнең исемлеге китерелә [2: 214–215]. Октябрь революциясенә кадәр һәм аннан соң

нәшер ителгән әсәрләре һәм басмалары, вакытлы матбугат һәм аерым җыентыкларга кергән хезмәтләре, аның турындагы әдәбият исемлеге исә 1975 елда нәшер ителгән ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең икенче томында урын ала. Галим турында библиографик белешмәне Г.Г. Батыршинаның «Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге» исемле монографик хезмәтендә дә табарга мөмкин [1: 141–153]. Бөек мәгърифәтченең тулы библиографиясе, беренче тапкыр Р. Исламов тарафыннан төзелеп, 2017 елда «Җыен» фонды тарафыннан чыгарылган «Шәхесләребез» сериясендә «Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык»та урын ала [3: 755–811]. Биредә аның матур әдәбият әсәрләреннән «Әбүгалисина кыйссасы», Оренбургка сәфәре уңае белән язылган «Сәфәр» дигән юлъязма-истәлеге, әхлак мәсьәләләренә багышланган «Тәрбия китабы», фәнни хезмәтләреннән татар укымышлылары хакында мәгълүматы, археология материаллары (Зөя өязе авыллары буенча), «Казан татарларының ислам диненә кадәр булган ышанулары һәм йолалары»ның тулы текстлары урнаштырылган. К. Насыйриның тууына 200 ел тулу уңаеннан китап, яңадан тулыландырылып, аерым басма булып дөнья күрә. «Каюм Насыйри: Биобиблиографик күрсәткеч» хезмәтендә Каюм Насыйриның биографиясе, нәшер ителгән әсәрләре, хезмәтләре, календарьлары, мәкаләләре, тормышы һәм иҗаты турында басылып чыккан хезмәтләр, гыйльми җыентыклар, якланган диссертация авторефератлары, мәкаләләр хакында бай мәгълүмат тупланган. Хронологик яктан алар 1860–2024 елларны үз эченә ала.

Р. Исламов искәртеп киткәнчә, теге яки бу галимнең иҗатына атап чыгарылган күп библиографияләрдә төгәллек җитешми. Бу бигрәк тә хезмәтнең күләме күрсәтелмәүдә, бит саннарын куймауда чагыла. Төрле телләрдә чыккан хезмәтләрнең библиографиясе я рус, я татар телендә бирелеп, җәя эчендә «на казахском языке» яисә «казах телендә» дип ачыклык кертелә. Рәмил әфәнде хезмәт нинди телдә басылган, библиографиясе дә шул телдә булырга тиеш дип саный. Тәкъдим ителгән китапта татар, башкорт, казах, мари, рус, таҗик, төрек, төрекмән, үзбәк, француз телләрендәге 970 берәмлек чыганак тупланган һәм төп нөсхәләрендә бирелгән.

Биобиблиографик күрсәткеч Р. Исламовның «Каюм Насыйрины өйрәнү һәм аның биобиблиографиясе» дигән кереш мәкаләсе белән ачыла. Мәкаләдә К. Насыйриның тәрҗемәи хәле яктыртыла: автор аның эшчәнлеге, яшәгән адреслары, Казанда кемнәр белән аралашкан һ. б. турында мөмкин кадәр тулы мәгълүмат бирергә тырышкан. Билгеле булганча, К. Насыйри гомер буе фәнни-гамәли эшчәнлек алып барган. Ул төрле фәннәрдән хәбәрдар булган. Аның табиблык, сызым, рәсем ясау, китап төпләү, балта һәм тимер эшләре белән шөгыльләнүе дә мәгълүм. Күрсәткечтә алар төркемләп бирелгән. Хезмәтләре һәм әсәрләреннән татар телендә «Әнмүзәҗ», «Әхлак рисаләсе», «Иҗек», «Кырык бакча», «Утыз вәгазь», башкорт телендә «Әбүгалисина», рус телендә «Мифология казанских татар», «Избранные произведения»

һ. б. турында этрафлы мәгълүмат бирелгән. Барлыгы 102 берәмлек урнаштырылган. Алар арасында кайбер хезмәтләренең төрле елларда 4–5 тапкыр басылганнары да бар.

Билгеле булганча, К. Насыйри – хәзерге татар әдәби теленә нигез салучыларның берсе, аның «Кыскача татар нәхүе» – шуның ачык мисалы. Ул милли этнографияне үстерүгә дә зур өлеш кертә, татар этнографиясенә караган хезмәтләрендә халкыбызның тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен яктырта. К. Насыйри татар халык авыз иҗатын да өйрәнә, ләкин үзе җыйган материалларны фольклор җыентыклары итеп чыгару мөмкинлеге булмаганлыктан, аларны кайбер хезмәтләрендә махсус бүлекләр рәвешендә урнаштыра. Мәсәлән, 1884 елда нәшер ителгән «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» җыентыгының кырыгынчы раузасы (бүлеге) 27 табышмак, 117 кыска җыр, 3 бәет, 215 мәкаль һәм әйтемне үз эченә ала. Бу хезмәттә автор һәр жанрга кыскача билгеләмә бирә. Галимнең халык авыз иҗатына, Казан тарихына, халык педагогикасына һ. б. өлкәләргә караган хезмәтләре күрсәткечнең беренче өлешендә тулы тасвирлана.

1871 елда К. Насыйри беренчеләрдән булып өстәл календаре чыгара башлый. Календарьлары һәм үзе язган мәкаләләре турында мәгълүматны күрсәткечнең икенче өлешендә табып була. Монда 24 календарьның аннотацияләре, галимнең татар һәм рус телләрендә 123 мәкаләсе тупланган.

К. Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты күп кенә галимнәр тарафыннан өйрәнелә һәм бәяләнә. Мөхәммәт Гайнуллин аның татар телендә дөнья күргән аерым хезмәтләренең библиографик күрсәткечен төзи. М. Гайнуллин һәм башка галимнәрнең К. Насыйри турында татар һәм башка телләрдә язылган хезмәтләре һәм мәкаләләре турында мәгълүмат күрсәткечнең өченче өлешендә урын ала. Күренекле мәгърифәтченең үзе һәм эшчәнлеге хакында тугыз монография (татар телендә – биш, рус телендә – дүрт), унөч фәнни җыентык дөнья күргән, тел, әдәбият, математика буенча дүрт кандидатлык диссертациясе якланган.

Каюм Насыйрига багышланган «Каюм Насыйри: иллюстрацияле персональ энциклопедия» – беренче персональ энциклопедиянең дөнья күрүе исә – татар халкының фәнни-мәдәни тормышында зур вакыйга. Аның төп максаты да – галимнең фәнни-мәдәни мирасын саклау, өйрәнү һәм киләчәк буыннарга тапшыру.

Әлеге хезмәт К. Насыйриның тәрҗемәи хәленә һәм күпкырлы эшчәнлегенә багышлана. Энциклопедиядә галимнең фәнни хезмәтләре, педагогик эшчәнлеге, әдәби иҗаты, шулай ук татар халкының аның тарафыннан фәнни нигездә өйрәнелә торган этнографиясе һәм фольклоры турында мәгълүматлар тупланган.

Персональ энциклопедия тугыз юнәлешкә караган мәкалә һәм белешмәләрне үз эченә ала:

1. Галимнең исән чагында дөнья күргән китапларына һәм рус телендә язылган мәкаләләренә энциклопедик белешмәләр.

2. К. Насыйриның еллык календарьлары. Һәр календарьда аның тарафыннан язылган мәкаләләрнең кыскача эчтәлеге күрсәтелә.

3. К. Насыйриның педагогик эшчәнлеге. Галимнең тормышчынбарлыкны чагылдыру үзенчәлекләре, дини-әхлакый карашлары да игътибар үзәгенә алына.

4. Галимнең нәселе, туганнары, замандашлары, укучылары. Алар К. Насыйриның үз нәселе турындагы язмалары, галим хакында авылдашлары һәм замандашлары язып калдырган истәлекләр, китапханә, архив, музей фондларында саклана торган документлар һәм иллюстратив материаллар нигезендә ачылган.

5. К. Насыйриның татар тел белеме, әдәбияты, фольклоры, тарихы, этнографиясе һәм табигыять белеме өлкәләрендәге эшчәнлеге.

6. К. Насыйриның тәрҗемәи хәлен һәм фәнни эшчәнлеген өйрәнүгә өлеш керткән галимнәр хакында белешмәләр. Хезмәттә мәгърифәтченең тормышы һәм иҗаты белән бәйле Гыйльми үзәк чаралары, аның юбилей даталарына бәйләп нәшер ителгән җыентык материаллары да искә алына.

7. К. Насыйри шәхесе һәм иҗатының татар мәдәниятенең төрле өлкәләрендә – сынлы сәнгатьтә (портретлар, бюстлар), театр һәм әдәбиятта яктыртылышы.

8. К. Насыйри тормышы белән бәйле урыннар: Казан губернасының Зөя өязе авыллары (шул исәптән, Югары Шырдан (хәзер Кече Шырдан), Олы Ачасыр, Бәчек, Күгеш һ. б.), Казан шәһәре, Сәгыйд бистәсе, Мәкәрҗә ярминкәсе һ. б., ул яшәгән йортлар, укыган мәдрәсәләр, эш урыннары; шулай ук Казандагы, Яшел Үзән районындагы музейлар, аның исемен йөрткән институт, мәктәп, урам һ. б. турында мәгълүмат.

9. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге премиясе лауреатлары (аерым шәхесләр һәм коллективлар) эшчәнлеге.

Кушымтада ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге премиясе лауреатлары исемлеге, шулай ук К. Насыйриның Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кульъязма һәм сирәк китаплар бүлеге һәм ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фондларында сакланган хезмәтләре, кульъязмалары һәм аңа кагылышлы материаллар исемлеге китерелгән.

Басманың структур һәм композицион төзелешенә килгәндә, энциклопедия Каюм Насыйриның тормыш юлы һәм эшчәнлегенә багышланган күләмле мәкаләдән башлана. Төп өлешендәге мәкаләләр һәм белешмәләр алфавит тәртибендә урнаштырылган. Мәкаләләрнең шактый өлеше сылтамалар белән ныгытылган. Мәкалә ахырында чыганаклар, әсәрләр һәм әдәбият исемлеге урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан эшләнгән «Каюм Насыйри: Биобиблиографик күрсәткеч» һәм

«Каюм Насыйри: иллюстрацияле персональ энциклопедия» – фәндә, мәдәнияттә кирәкле, күп мәгълүматлы, мәртәбәле хезмәтләр. Әлеге басмалар К. Насыйриның тормышын, фәнни эшчәнлеген, иҗатын киңрәк, тулырак аңларга, бәяләргә һәм халкыбыз мирасын киләчәк буыннарга түкми-чәчми тапшырырга ярдәм итәчәк.

**Әдәбият**


1. *Батыршина Г.Г.* Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге. Казан: КДАТУ нәшр., 2007. 171 б.
2. Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри [Сборник к 150-летию со дня рождения]. Казань: Институт языка, литературы и истории, 1976, 216 с.
3. Каюм Насыйри: әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык / [төз. Рәмил Исламов]. Казан: Җыен, 2017. 815 б.
4. Каюм Насыйри, 1825–1945: тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары) / [җав. ред. Ш.А. Рамазанов]. Казан: Татгосиздат, 1948. 146 б.
5. Татар халкының атаклы галиме, мәгърифәтчесе һәм язучысы Каюм Насыйри (1825–1902): әдәбият исемлеге / [төз. З.Ш. Хәбибуллина; ред. Р.З. Мөхитдинова]. Казан, 1952. 12 б.



***Зәкиева Резеда Госман кызы,***
*ТР ФА М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының цифрлы-электрон ресурслар бүлеге фәнни хезмәткәре*

***Закиева Резеда Гусмановна,***
*научный сотрудник отдела электронно-цифровых ресурсов Института татарской энциклопедии и регионоведения имени М. Хасанова АН РТ*

*rezedz@yandex.ru*